УРТАК ЭШ
Сарманда милләт, тел, дин турында фикер алыштылар
> 2

ИХЛАС КЕШЕ
Хезмәттәшебез Рәшит Фәтхрахманов җиденче дистәсенә аяк баса
> 3

ДӘНИФ ШӘРӘФЕТДИНОВ:
«Көн туса да, кич җитсә дә, бөтен таянычым – ышаныч»
> 4

ИГЕЛЕКЛЕ ГАМӘЛ
Кан бирергә килгән донорларны тәм-том, җыр-моң белән каршыладылар
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 160 (28933) | Шимбә | 29 октябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

ӨЧ АРШЫН ҖИР

Мәетне җирләү хезмәтләренә үлгән кешеләр турындагы мәгълүмат тарату, мәрхүмнәрнең якыннарыннан өстәмә акча алу, җир бүлеп бирүдә закон бозу очраклары. Татарстанның Иҗтимагый палатасында халыктан килгән сорауларны кабул иткәндә шушы һәм башка проблемалар калкып чыкты. Иҗтимагый палатаның җәмәгать контроле буенча комиссия рәисе Артур Мустаев бу мәсьәләгә юктан гына игътибар бирмәгәннәрен әйтте – бу өлкәдә халыкны борчыган, кызыксындырган сораулар күп.

Шалтыратучыларның берсе башкаладагы Арча зиратының ябылу-ябылмавы белән кызыксынды. Аның соравына Казанның ритуаль хезмәтләрне оештыру идарәсе җитәкчесе урынбасары Ленар Абдуллин ачыклык кертте.

– Ул тулы булса да, ябылмады, – диде ул. – Әгәр ябылган дигән статусы булса, бөтенләй беркемне дә җирләргә ярамас иде. Хәзерге вакытта анда моңа кадәр урын алып калган кешеләрне яки 15 ел элек мәрхүм булганнарның каберләре өстенә җирлиләр. 15 ел эчендә мәет таркала, шул вакыт узгач, башка кешене җирләргә ярый. Шуннан да иртәрәк ярамый. Һәм бу бары тик кабер өчен җаваплы кешенең рөхсәте белән генә эшләнә. Ягъни ул мәетне җирләүне үз өстенә алган яки каберне саклауны үзенә рәсмиләштергән кеше була ала. Кайбер кешеләр зираттагы агачларны чистартып, мәрхүмне ул урынга да җирли ала. Тик бу очракта ул агач чистарту чыгымнарын үзе күтәрә.

Ә менә билгеле булмаган, ташландык хәлдәге каберләргә кагылырга ярамый. Чөнки бу беренче чиратта куркынычсызлык белән бәйле. Беренчедән, анда кем, нинди шартларда җирләнгән булуы, ни сәбәпле үлүе билгеле түгел.

– Бәлки анда куркыныч авырулы кеше күмелгәндер? Казып алган очракта, ул тирә-юньгә таралып, тагын да күбрәк кеше үлеменә китерергә мөмкин. Мәетне казып алу бары тик Роспотребнадзор рөхсәте белән генә башкарыла, – диде Ленар Абдуллин.

Чаллыда яшәүчене кеше мәрхүм булуга ук аның якыннарына бер-бер артлы төрле ритуал агентлыкларының үз хезмәтләрен тәкъдим итеп шалтыратуы борчый булып чыкты.

– Якынын югалткан кешенең аңы болай да томаланган була, җитмәсә, аңа берничә агентлык шалтыратып, баш катыра. Димәк, кешенең үлүе турындагы мәгълүмат кемнәндер тарала булып чыга бит? Моның өчен кем җаваплы? – дип сорады ул.

Халык сорауларын кабул итүчеләр ханымның соравына ачык кына җавап бирмәсәләр дә, мондый очраклар булуын инкарь итмәделәр. Бер эш хәтта судка кадәр барып җиткән. Ул вакытта үлгән кеше турындагы мәгълүматны полициянең участок хезмәткәре тапшырган булып чыккан.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Һәр очракны аерым карарга кирәк. Әйтик, кайгыдан югалып калган кешеләргә ярдәм итәргә теләп, полиция хезмәткәре мәетне җирләү хезмәтенең телефоннарын да бирергә мөмкин. Шуңа күрә без полиция һәм медицина учреждениеләре хезмәткәрләре уңга-сулга мәгълүмат тарата, дип берничек тә әйтә алмыйбыз. Гомумән алганда, республикада мәетне җирләүдә коррупция очраклары аз, – диде Ленар Абдуллин.

Закон бозу очраклары димәктән, Татарстан Прокуратурасының социаль өлкәдә законнарның үтәлешен күзәтү бүлеге башлыгы Айрат Галимов әйтүенчә, республиканың 30 районында мәетләрне җирләү белән шөгыльләнүче махсус хезмәтләр юк. Закон бозу очраклары шулай ук җир бүлеп бирүдә, бер кабергә берничә мәетне күмүдә күзәтелә. Татарстан Прокуратурасы уздырган тикшерү нәтиҗәләре бу өлкәдә 128 закон бозу очрагын ачыклаган. Аларның 46сы хәл ителгән. 5 эш судка тапшырылган, бер очрак буенча җинаять эше ачылган.

Татарстанның суд-медицина экспертизасы бюросы җитәкчесе Марат Тимерҗанов әйтүенчә, мәетләрне ярдыру буенча да халыктан сораулар күп килә. Шалтыратучылар арасында да бу мәсьәлә белән кызыксынучы кеше булды. Марат Тимерҗанов сүзләренчә, әгәр дәвалау учреждениесендә кешенең диагнозында ачыклык юк икән (әйтик, яшьли кинәт үлсә яки моңа кадәр табибларга күренмәгән булса), яки көч кулланып үтерүдә шик булса, мәетне һичшиксез яралар. Бу хезмәтләр бушлай эшләнелә. Әгәр кеше өлкән яшьтә булса, һәм хроник авырулары үлү турындагы белешмә бирер өчен җитәрлек дип табылган очракта, белешмәне мәетне беркая да алып бармыйча гына бирәләр. Ниндидер шик туса яки диагноз куйганда билгесезлек килеп чыкса, мәетне яралар. Хокук саклау органнарының көч кулланып үтерүдә шиге туса, суд-медицина экспертизасына юллыйлар.

Ленар Абдуллин, якын кешесен югалткан очракта, махсус хезмәтләргә мөрәҗәгать итүчеләр артуын әйтте. Алар документларны җыю һәм мәетне җирләү буенча барлык мәшәкатьләрне үз өсләренә ала. Ә инде бәяләргә килгәндә, һәркем юрганына карап аягын суза. Якынын югалтучылар арасында 10 меңлеккә дә, 120 мең сумлык табутка да заказ бирүчеләр бар.

– Якынын җирләргә финанс мөмкинлеге булмаган кешеләр дә бар. Кызганыч, андыйлар шактый. Андый очракта мәрхүмне махсус агентлыклар иң аз чыгымнар белән җирли. Бүген аның бәясе – 6964 сум. Һәм бу очракта мәрхүм, нинди милләт вәкиле булуына карамастан, бары тик табутта җиргә иңдерелә. Шуны да әйтеп узасым килә: мәетне җирләү өчен урын сатып алынмый. Әгәр җир өчен акча сорыйлар икән, бу закон бозу булып санала, – дип аңлатты ул.

План үтәлгән

Россия Президенты Владимир Путин илнең оборона министры Сергей Шойгу белән очрашты. Министр дәүләт башлыгына өлешчә мобилизация турында хисап тотты.

Сергей Шойгу сүзләренчә, Россиядә өлешчә мобилизация тәгәлләнгән. План буенча каралган 300 мең кешене мобилизацияләгәннәр. Владимир Путин өстәп әйткәнчә, иң мөһиме хәзер – аларны әзерләү. 218 меңләп кеше әзерлек этабын уза инде.

Оборона министры Сергей Шойгу әйтүенчә, хәзер инде хәрбиләр сафына килешү буенча хезмәт итүчеләрне һәм теләге булганнарны кабул итәчәкләр. Өлешчә мобилизация кысасында, башкарма хакимият органнарыннан да 1300 кеше хәрби хезмәткә алынган. 27 меңнән артык эшмәкәргә чакыру килгән. Мобилизацияләнгәннәрнең уртача яше – 35. Үз теләкләре белән китүчеләрнең саны 13 меңгә җиткән. Махсус хәрби операция зонасына 82 мең кешене җибәргәннәр.

Форсаттан файдаланып, Владимир Путин хәрбиләр сафына кушылганнарга рәхмәтен белдерде.

Әйбәт күрсәткеч

Россия банкы төп ставканы 7,5% күләмендә саклап калу турында карар кабул иткән. Банк хәбәренә караганда, хәзерге вакытта бәяләрнең чагыштырмача түбән булуы еллык инфляциянең акрынаюына китерә. Ел азагына инфляциянең 12,0–13,0% тәшкил итүе көтелә. Россия банкы фаразына караганда, өлешчә мобилизация алдагы айларга кулланучылар ихтыяҗын һәм инфляцияне киметәчәк.

Исегезгә төшерәбез: банк сентябрь аенда төп ставканы 7,5 процентка кадәр киметте. Июльдә ул 8% күләмендә калдырылган иде. Шул чагында төп ставка берьюлы 1,5 пунктка киметелде. Моңа кадәр – 10 июньдә ул 1,5 процентка төшерелеп, 11дән 9,5 процентка калдырылды. Украинада махсус хәрби операция башланганчы шундый ставка иде.

Кыш кайчан башлана?

Суыта. КФУ профессоры Юрий Переведенцев әйтүенчә, киләсе айның беренче көнендә карлы яңгыр көтелә. Көндез +2 градуска кадәр җылы булса, төнлә –1. «1 ноябрьдән бездә кыш алды чоры башлана. Яңа ай башында температура нык төшәргә, юеш кар яварга мөмкин. Күпьеллык күзәтүләргә караганда, Казанда гадәттә 19–21 ноябрь аралыгында кар ята. Шушы вакытта тәүлеклек уртача температура –5 градустан кими. Кар ятып, температура шушы күрсәткечкә кадәр төшүгә, кыш җитә», – дип аңлаткан ул.

Белгеч әйтүенчә, ял көннәрендә республикада болытлы һава урнашачак, урыны белән аз гына яңгыр, юеш кар. Көндез һава температурасы +7 градус чамасы булачак. Якшәмбе – 30 октябрьдә һава торышының нык бозылуы көтелә. Секундына 15–20 метр, урыны белән 23 метр тизлектә көчле җил, яңгыр. Көндез +2…+7, төнлә –2…+3 градус.

Ярдәм янәшә!

Бергә җиңелрәк

«Ярдәм янәшә!» иҗтимагый хәрәкәтенең колл-үзәгенә юл тотканда, күршеләрендәге бер оешмада эшләүче туташ белән сөйләшеп киттек. Активистларның эшенә соклануын ул да яшерми. «Аларның үз йөрәкләре аша нинди авырлыклар уздырганын белсәгез икән! Үзләре шундый яшьләр, әмма кеше сорауларына битараф түгелләр. Ә аларга төрле сораулар белән мөрәҗәгать итәләр бит...» – ди ул. Колл-үзәкнең тынгысыз эшен без дә күреп кайттык.

Иҗтимагый хәрәкәт координаторы Тимур Сафин сөйләвенчә, аларның төп бурычы – мобилизациягә эләккәннәрнең туганнары-якыннарына төрле яклап ярдәм итү. Колл-үзәк тә күптән инде шалтырату, мөрәҗәгатьләр җыю урыны гына түгел. Координатор да аны элемтә, коммуникация кору мәйданы дип саный.

– Киенгәнме, ашаганмы, ятар урыны йомшакмы – хәрбиләрнең туганнары көнкүрешкә кагылышлы сорауларга өстенлек бирә. Барысы да кайгыра, билгеле. Алар белән бергә без дә кайгырабыз, шуңа да кулдан килгәнчә булышырга телибез. Башкарган эшләребез күп иде, хәзергесе – иң киеренкеседер. Җәмгыятьтә дә сизелә ул. Әмма без бергә бит. Берләшсәсе, бергә эшлисе генә кала. Без бик күп оешмалар белән элемтәдә торабыз. Бу – «Бердәм Россия» партиясенең кабул итү бүлеге дә, Бөтенроссия халык фронты да, «Халык контроле» дә. Безнең бурыч – мөрәҗәгатьләрне игътибарсыз калдырмау, җавабын табу, – ди ул.

«ВТ» хәбәрчесе барган көнне колл-үзәктә 5 волонтер мөрәҗәгатьләр кабул итеп утыра иде. Тимур Сафин сүзләренчә, аларның санын, вазгыятькә карап, 20гә кадәр җиткерү мөмкинлеге дә бар. «Волонтерлар әзерлек уза. Аларга афәрин диясе кала. Сорауларны кабул итүдә профессиональ психолог та эшли», – диде Тимур Сафин.

Мөрәҗәгатьләрне, төрләренә карап, тиешле урыннарга юллыйлар икән.

– Әйтик, түләүләргә карата сорау булса, аны Социаль яклау министрлыгына юллыйбыз. Хокукый сорауларны Кеше хокукларын яклау идарәсе кабул итә. Көнкүрешкә бәйле ярдәм кирәк икән, волонтерлар хәрәкәте эшкә җигелә. Психологик консультация сорыйлар икән, «Кызыл хач» оешмасына мөрәҗәгать итәргә була. Дини хезмәтләр дә актив эшли. Әйтик, епархиянең «Милосердие»се, «Ярдәм» мәчетенең үз фонды бар, – ди ул.

Автор фотосы

21 февральдән башлап, барлык хезмәтләрне дә исәпкә алып, колл-үзәк 28 меңләп мөрәҗәгать кабул иткән. Күбесе – аңлату, мәгълүмат бирү таләп иткән сораулар. 10 проценты – конкрет очраклар.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Павел КРУПНИК, Санкт-Петербургның Закон чыгару җыены депутаты:

Соңгы елларда Россиядә үзебезнең ил кадрларын IT һәм компьютер программалаштыруы өлкәсендә әзерләүнең мөһимлеге турында сөйләшүләр бара. Әмма мондый белгечләрне, кагыйдә буларак, профильле уку йортлары гына әзерли. Программалаштыруны өйрәнүне мәктәптә үк башларга кирәк. Бу ил икътисадына белгечләр әзерләүдә ярдәм булыр иде.

(«Парламентская газета»дан)

РОССИЯДӘ – АВЫЛДА ЯШӘҮЧЕ ХАЛЫК САНЫ

2021 елда үткәрелгән Бөтенроссия халык санын алу нәтиҗәләре буенча, авыл халкы 37,1 миллионны тәшкил итә.

153 мең авыл һәм сала

- **4%** – 1000нән артыграк кеше яши
- **27%** – 100–1000 кеше яши
- **69%** – 100дән азрак кеше яши
- **16%** – теркәлгән халкы юк

Гомерлек җәза

Татарстан Югары суды Игорь Птицинны гомерлек төрмә җәзасына хөкем иткән. Судта ул соңгы сүзен җиткергәндә үзенә иң кырыс җәза бирүләрен сораган, корбаннарының туганнарыннан гафу үтенгән. Татарстан прокуроры Илдус Нәфыйков Птицинны гомерлеккә ирегеннән мәхрүм калдыруны таләп иткән. Моннан тыш аңа җәза үтү урынында (аерым режимдагы колониядә утырачак) психиатрда мәҗбүри дәвалану таләбе куелган. Суд шулай ук Птициннан 6 миллион сум күләмендә әхлакый зыян түләтү турында карар чыгарган.

Игорь Птицин 12 җинаять очрагында гаепле дип танылган. Болар – үтерү, көчләү. Тикшерүчеләр әйтүенчә, ул 2009–2017 елларда Казанның «Глубокое» күле тирәсендә, шулай ук Авиатөзелеш районында 17–35 яшьлек хатын-кызларга һөҗүм иткән. 3 кыз үлгән. Аның кулыннан барлыгы 7 кеше зыян күргән. Шул ук вакытта Птицин тикшерү барышында 29 кешегә һөҗүм иткәнлеген белдергән.

Кәбестә кыйммәт, кишер арзан

Узган атнада Татарстанда иң кирәкле яшелчәләрнең кайберләре кыйммәтләнгән. «Татарстанстат» мәгълүматларына караганда, бигрәк тә кәбестә бәясе күтәрелеп (3,23 процентка), аның килосы 17,63 сумга җиткән. Кыяр бәясе – 2,14 процентка (84,72 сум), помидор – 1,13 процентка (84,61 сум) арткан. Йомырка да нык кыйммәтләнгән – 4,5 процентка, хәзер аның дистәсе уртача 67,68 сум тора. Шулай ук ярым ысланган колбаса, маргарин һәм сөт хакы арткан.

Шул ук вакытта кишер бәясе, 2,51 процентка төшеп, 24,2 сумга калган. Башлы суган – 2,06 процентка (килосы – 25,6 сум), алма – 1,44 процентка (83,76 сум), балалар өчен коры сөт катнашмасы 1,43 процентка (килосы – 966,75 сум) арзанайган. Ярма һәм ит хакы үзгәрешсез калган.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Банкирлар һәм вампирлар

Язманы Владимир Путинның «Валдай» халыкара дискуссия клубындагы чыгышыннан кыска гына бер өзек китереп башлыйк әле. «Алда безне, – диде Кремль лидеры, – икенче Бөтендөнья сугышыннан соң күз алдына китереп булмаслык авыр унъеллык көтә». Владимир Владимировичны аз гына төзәтергә җөрьәт итәм: кешелек дөньясы үз тарихындагы иң куркыныч чорга аяк басарга тора.

Юк, юк, берәүне дә куркытырга җыенмыйм, вакыйгалар безнең ихтыярдан башка ага. Бары тик бер генә нәрсә белән юата алам: дәһшәтле давыл узып киткәннән соң, муллык һәм бәрәкәт дәвере башланачак. Андый чор кешелек тарихында бер булган инде. Кешеләр, мохтаҗларга бирергә дип, хәлиф Гомәр ибн Габделгазизгә күп акча күтәреп килгәннәр, сәдака бирерлек кеше табылмаган. Шуңа охшаш хәл киләчәктә кабатланачак әле. Әмма ул чорга исән-сау калып ирешү өчен нык тырышырга, тәкъвалыкны корал итәргә туры киләчәк. Бу юллар авторының да фикере әлеге очракта Путинныкына тәңгәл килә диярлек: иң катлаулысы – алдагы унъеллык. Без якынча гына әйтәбез, бәлки, биш, җиде, бәлки, унбиш елдыр. Чын дөресен бары тик Аллаһы Тәгалә генә белә.

Әлегә исә «Ни өчен кешелек дөньясы шундый дәһшәт алдында калды?» дигән сораугa җавап кына эзләргә тырышып карыйк. «Ватаным Татарстан»да без унөч еллар тирәсе элек ул җавапны «Вампирлар» дигән язмада биргән идек инде. Банкирларның, кешеләрне алдап, финанс сазлыгына өстерәп кертүләре нәтиҗәсендә глобаль җәмгыятьнең зур бәхетсезлекләр алдында калачагын саннар ярдәмендә дәлилләгән идек. Аларны хәзер кабатлап тормыйбыз. Банкирлар һәм вампирлар, гаҗәп охшаш яңгырый, шулаймы?

Процент капиталына киң юллар ача торган нәрсә бар. Ул – кәгазь акча. Хәзер электрон акча да инде. Боларны күпме теләсәң, шуның кадәр басып була. Шулай булгач, үзәк банклар төп ставканы күпме теләсә, шуның кадәр куя алалар. Әйтик, менә Үзбәкстанда ул бүген – 15 процент. Төп ставка 15 булганда, банклар кредитны 25–30 процент тирәсендә бирәләр. Тереләй туныйлар, әйеме? Хәер, төп ставка кечкенә булса да, бөлгенлектән коткармый. Европада, мәсәлән, ул нульгә якын иде, хәзер аны 2 процентка кадәр җиткерделәр. Ставка кечкенә булганда, бәяләр күтәрелә, инфляция котырына. Барыбыз да бөләбез. Көнбатыштагы инфляцияне, ягулык бәяләрен ишеткәнегез бардыр инде. Газ җитмәгәнгә түгел, акча күп булганга күтәрелә бәяләр. Ставканы күтәрә башлагач, бәяләр түбәнгә китте.

Икътисад буенча быелгы Нобель премиясен кемнәргә бирделәр әле? Акчаны күп басып, икътисадны коткарган банкирларга. «Коткару» дигәндә, олигархик капиталны саклап калуны күздә тоталар. Массалар бөлә, олигархлар байый. Моның нинди нәтиҗәләргә китерүен Путин сүзләре белән раслыйк әле. «Происходит захват рынков и ресурсов… Используя доллар как оружие, Запад дискредитировал институт международных финансов». Бу тезисны киңәйтеп, бик күп сөйләргә була. Кыска гына итеп әйтик: американнар, долларның дөньякүләм резерв валютасы булуыннан файдаланып, Җир шарының бар байлыгын үзләренеке итеп бетерә язды. Бераздан евро кертелгәч, европалылар да шуңа кушылды. Станоктан сан язылган кәгазьләрне күпме теләсәң, шуның кадәр чыгарасың да, теләсәң нефть, теләсәң алтын сатып ал. Кемнәр моңа каршы килә, Путин әйткәнчә, «цап-царап» итәсең дә, валюта резервларын талыйсың да аласың. Андый талауны Гыйрак, Ливия, Иран кебек илләр кичерделәр инде. Хәзер Россия йолкынды. Бүген дә әле без яшәгән дәүләт стратегик товарларын электрон долларларга сата һәм алмашка берни дә ала алмый диярлек. Технологияләр дә юк, технологик товарлар да. Автодилерлар, мәсәлән, яңа машиналар запасы бер-ике айлык кына калды, диләр. Немец брендлары складларда берничә дистә генә калган икән. 140 миллионлы бөтен илгә утыз-кырык машина нәрсә инде ул! Акча юклыктан түгел бит бу. Банклар хисабында эшкә ярамаган берничә йөз миллиард доллар һәм евро җыелды инде.

Америка банк капиталының болай кылануы (хакимиятләр исә һәрвакытта да банкирларга хезмәт итә) Азия, Африка, Латин Америкасы илләренә бер дә ошамый. Доллардан акрынлап баш тарту сәясәте мәйданга чыга. Әмма вазгыятьнең бөтен фаҗигасе шунда: барлык илләрнең дә резервлары долларда саклана. Кытайның – 3 триллион доллардан, Согуд Гарәбстанының 456 миллиард доллардан артык байлыгы – американ кәгазьләрендә. Болар, билгеле, доллар прессы астыннан чыгып, башка валюталарга күчмәкче булалар, әмма доллардагы резервларын берьюлы алыштырсалар, доллар системасы җимерелеп төшәчәк, һәм барысы да ыштансыз калачак. Шәп эләктергән АКШның Федераль резерв системасы дәүләтләрне! Доллардан баш тарту дөньякүләм финанс фаҗигасе китереп чыгарачак. Долларны резерв валютасы итеп тануны дәвам иттерү – Вашингтонның басымчаклыгына түзү, алар санкция керткәннән соң, Россия хәлендә калу дигән сүз ул. Ике начарның икесе дә начар, кайсын сайларга белмәссең.

Бу тупиктан чыгу юлын һәркем эзләргә тырыша. Физик затлар акчаларын алтын коелмага әйләндермәкче була. Россия банкларында алтын коелмалар дефициты бүген. Алтын сатып алган өчен НДСны бетерү ажиотаж тудырган. Алтын бар һәм күп ул әлегә, ләкин кечкенә күләмле коелмалар юк. Элек алтын коелмаларны федераль чиновниклар һәм олигархлар гына ала иде. Алар килолап ала, ә гади халыкның акчасы берничә унциялек коелмага гына җитә. Килолы коелмалар бар, граммлысы юк, кыскасы. Америка спекулянты Роберт Кийосаки яңа гына: «2023 елның гыйнварында, ФРС капитуляция ясагач, доллар җимерелә. Хәзер үк алтын, көмеш, биткоин сатып ал», – дип, коткы тарата. Алай ук тиз булмас дип уйлыйм мин үзем, әмма доллар системасының түнтәрелеше якыная инде. «Валдай»дагы нотыгында Путин да шул хакта хәбәр итә. Бу – банкирларның безне зур фаҗигагә илтеп тыгулары булачак.

ҖИРДӘН – КҮККӘ

tatarstan.ru

«Лаешта яшьләр белән эшли беләләр». Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин «Бердәм Россия» көне уңаеннан Лаеш районында узган очрашуда әнә шулай дип белдерде. Ул халыкның социаль тормышы, белем һәм тәрбия бирү, һөнәргә өйрәтү оешмалары эшчәнлеге белән танышты. Соңыннан башкарылган эшләргә нәтиҗә ясадылар.

Фәрит Мөхәммәтшин башта Усад бистәсендәге «Сәламәт буын» күппрофильле лицейда булды. Монда балаларның белеме генә түгел, сәламәтлеге, тәрбиясе турында да кайгырталар. Биредә «ГТО мәктәбе» оештырылган, укучылар нормативлар буенча тест уза. Шулай ук «Сәламәтлек мәктәбе» дә эшли. Балаларның туклануын, сәламәтлеген контрольдә тоталар.

Уку йорты директоры Владимир Трошин әйтүенчә, биредә 800дән артык укучы белем ала. 1 нче сыйныфка килүчеләр саны күп, быел хәтта «П» сыйныфына кадәр ачканнар. Лицейда социаль-икътисад, инженер-техник юнәлешләрдә профильле сыйныфлар булдырылган.

Фәрит Мөхәммәтшин дәресләрдә дә булды, шулай ук ашханәгә дә кереп чыкты. Анда 4 нче сыйныфларның төшке аш вакыты иде. «Тәмлеме?» – дигән соравына бертавыштан «тәмлеееее…» дип җавап бирделәр. Очрашуга җирле «Әтиләр берлеге» әгъзалары да килгән иде. Берлек рәисе Азат Гайнетдинов сөйләгәнчә, лицейның аскы катында махсус спорт залы оештырганнар. Монда әтиләр һәм балалар бергә көрәш, фитнес белән шөгыльләнәләр. Бүгенге заманда әтиләрнең мәктәпкә килеп, укучылар тәрбиясенә өлеш кертүен Фәрит Мөхәммәтшин да хуплады. Аның каравы Усадта мәдәният йорты юк икән. «Әтиләр берлеге» балаларга шартларны тагын да яхшырту өчен өстәмә бина булдыруны сорады.

Лаеш техник-икътисад техникумы 2016 елдан ресурс үзәге буларак эшли. Монда республиканың авиация комплексы өчен белгечләр дә әзерләнә икән. Ике ел элек очкычсыз авиация системаларын эксплуатацияләү белгечлегенә студентлар кабул итә башлаганнар. Мөгаллим Атаҗан Нарбаев әйтүенчә, әлеге белгечлеккә килүчеләр күп. Быел 1 нче курска 30га якын кеше җыйганнар. «Бу юнәлешнең киләчәге бар. Киләчәктә очкычлар пилотсыз гына оча башлаячак», – дип өметләнә ул.

Техникум директоры Эльвир Якупов үзе җитәкләгән уку йортының илдә уникаль булуы белән дә горурланып алды. «Без бүген Россиядә булмаган әйберләрне эшләдек. Очкычларга хезмәт күрсәтү өчен махсус рөхсәт кирәк. Бездә укып чыккан белгечләрдә әнә шундый рөхсәт булачак», – диде директор. «Мин моны белмәгән идем. Лаеш авыл хуҗалыгы районыннан җитештерүче төбәккә әйләнә», – дип куйды Фәрит Мөхәммәтшин.

Дәүләт Советы Рәисе техникумнан соң «Ак тау» яшьләр үзәгендәге яшьләр белән дә аралашты. Монда йога, бию, фитнес белән шөгыльләнү өчен универсаль зал бар. Әлеге үзәк командасы 1,8 миллион сумлык грант откан.

Эш сәфәре ахырында Мөхәммәтшин Лаеш районы активы белән очрашты.

– «Бердәм Россия» көннәрен район һәм шәһәрләрдә уздыру күркәм традициягә әйләнде. Анда иң борчый торган мәсьәләләр, яхшы тәҗрибәләр белән уртаклашабыз. Мондый авыр чорда, беренчедән, бердәмлек, ярдәмчеллек, икенчедән, тырыш халкыбызның хезмәтен күреп, бәя бирү кирәк, – диде Фәрит Хәйруллович. – Лаешта күргәннәребез, ишеткәннәребез гаҗәпләндерде. Яшьләр, волонтерлар белән җитди эш алып барыла.

Парламент башлыгы лаешлыларны торак төзү, авыл хуҗалыгы товарлары җитештерү буенча алдынгы булуы өчен дә мактады. «Авыл кешеләре гореф-гадәтләрне саклау буенча да хөрмәт уята. Быел республиканың авыл хезмәтчәннәре көче белән кырлардан 5 миллион тонннадан артык бөртекле культуралар җыеп алынды», – дип, сала халкына рәхмәтен белдерде.

Сәрия МИФТАХОВА

ХӘТЕР КӨНЕ

30 октябрь – Сәяси репрессияләр корбаннарын искә алу көне. Моңа бәйле рәвештә Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева мөрәҗәгать белән чыкты. «Әлеге кайгылы дата илебез тарихында коточкыч вакыйгаларны, миллионнарча гаиләгә кагылып, тулы бер буынның язмышын мәңгегә үзгәрткән авыр сынауларны искә төшерә. Татарстаннан сәяси репрессияләнгән илле меңнән артыграк кешенең исеме һәм аларның гаиләләре Татарстан Республикасы Хәтер китабының 28 томында мәңгеләштерелгән.

Еллар уза, буыннар алышына. Безнең бурыч – яшь буынга узган елларның шушы фаҗигале, шомлы вакыйгалары турында дөреслекне җиткерү, аларны ватанпәрвәрлек рухында, үз иленә тугры итеп тәрбияләү. Узгандагыдан башка киләчәк юк.

Татарстанның барлык районнарында сәяси репрессияләр барышында һәлак булган һәм зыян күргән якташларыбызга багышланган истәлекле чаралар, акцияләр узачак.

Намусын, горурлыгын, тормышка мәхәббәтен саклап, хаксыз гаепләүләрнең барлык кыенлыкларын үз башыннан кичергәннәрнең һәркайсына озын гомер, нык сәламәтлек телим!»

Бергә җиңелрәк

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Баштарак мобилизациягә бәйле хокук бозуларга карата сораулар күп килде. Хәзер исә җәмгыятьнең берләшүен күрәбез. Күпләр көченнән килгәнчә ярдәмләшергә әзер булуын белдерә. Бу – аерым кешеләр дә, оешмалар да. Әйтик, кемдер кайнатмалар җибәрергә тели, кайсылары, тонналап бәрәңге белән булышырга ярыймы, дип сорый. Ярдәмнең төрлеләре бар.

Барысын да акча, азык-төлек, кием-салым, рухи сораулар гына кызыксындырмый анысы. Волонтерлар сөйләвенчә, шушы көннәрдә өлешчә мобилизациягә эләккән берәү үзенең дүрт аяклы дустын – зур этен кая урнаштырырга белмәгән. Этнең төре дә үзенчәлекле, теләсә кемгә калдырырлык түгел, мөрәҗәгать итүченең туган-тумачалары да юк, ди. Приютлар инде тулы дип борчылган ул. Волонтерлар хуҗаны тынычландыра алган: тугры дуска яңа оя тапканнар. Хуҗасы белән очрашырга насыйп булсын инде аңа да. Сагынып көтәр йорт хайванының булу да еракларда йөргәндә өшегән күңелләргә җылы өсти бит әле ул кайчагында…

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

СҮЗ УҢАЕННАН

Барлык кызыксындырган сорауларга җавапны «Ярдәм янәшә!» хәрәкәтенең рәсми сайтында (ярдям.рф) табарга мөмкин. Шулай ук «кайнар» элемтә телефон номеры да бар. 8 (800) 350-02-15 номеры буенча шалтыратуларны иртәнге 9дан кичке 6га кадәр кабул итәләр.

Шулай ук бу QR-код ярдәмендә матди ярдәм күрсәтергә мөмкин.

ГАЗ КӨТКӘНДӘ

Республикада газлаштыру дәвам итә. Бүген Татарстанда газ кертү өчен 29 мең 43 кешедән гариза алынган. Шуларның 13 мең 747се белән килешү төзелгән инде. 8 мең 752сенең капка төбенә кадәр газ кергән.

Республиканың Арча, Чирмешән, Түбән Кама, Питрәч, Бөгелмә, Спас, Баулы, Аксубай, Минзәлә, Алабуга, Тәтеш, Балык Бистәсе, Мамадыш, Азнакай, Әгерҗе районнарында газ кертү эшләре әле дә аксый икән. Ә менә Кукмара, Буа, Апас, Балтач, Чистай, Чүпрәле, Яңа Чишмә районнары актив эшли. Аларда инде газлаштыру эшләренең яртысыннан артыгы тәмамланып килә. Бу хакта Татарстанның Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Дмитрий Сапожников сөйләде.

– Газ кертү өчен йорт хуҗасы мөрәҗәгать итәргә тиеш. Шунысы да бар: зәңгәр ягулык капка төбенә кадәр генә бушлай килә. Өйгә тоташтыру чыгымын йорт хуҗасы үзе күтәрә. Аның суммасы төрле җирдә төрлечә булырга мөмкин. Бар да кирәкле җиһазлар бәясеннән тора.

Дмитрий Сапожников әйтүенчә, капка төбенә килгән газны йортка керткәндә мәшәкатьләр килеп чыгарга мөмкин. Тоташтыру, уртача алганда, 180 мең сумга төшә. Әнә шул шалт итеп чыгарып бирергә акча булмау кешене сабыр иттерә. Әле бит дәүләт аз керемле, авыр хәлдә яшәүче һәм башка төр категория кешеләргә бирә торган субсидия акчасын алыр өчен дә, башта тиешле сумманы түлисе, аннан соң компенсация кайтканын көтәсе бар. Белгечләр, моннан чыгу юлларын эзлибез, дип ышандыра. Якын киләчәктә Татарстанның Тарифлар буенча дәүләт комитеты белән «Газпромтрансгаз Казан» оешмасы бергәләп сөйләшергә җыена. Моның да бер тәртибен булдыру кирәк. Бу хакта да уйлап бетерәчәкләр.

Газ тоташтыру өчен гаризаны Дәүләт хезмәтләре порталы аша да, горгаз, райгаз оешмаларына да тапшырырга була. Гаризада паспорт, СНИЛС мәгълүматларын, телефон номерын күрсәтергә, йортка һәм җир кишәрлегенә хокук билгели торган документларның күчермәсен кушымта итеп бирергә кирәк. Кертү вакытын газ оешмасы билгели. Төгәлрәк мәгълүматны 8 800 201 04 04 телефоны аша белешергә мөмкин.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ДИН – ТЕЛНЕ, ТЕЛ ДИННЕ САКЛЫЙ

Туган телне саклау һәм үстерүдә дин, татар телендәге элмә такталарда хаталар, кадрлар мәсьәләсе. Татарстан Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясенең чираттагы зона семинар-киңәшмәсендә әнә шулар турында сөйләштеләр. Бу юлы ул Сарманда узды.

sarman-rt.ru

– Бүгенге тормышыбыз гади генә түгел. Җаваплы, мәшәкатьле, борчулы чорда яшибез. Тик телебез мәсьәләсе, нинди генә халәттә булсак та, безнең эшчәнлегебездә иң алда булырга тиеш, – диде комиссия рәисе Марат Әхмәтов. – Президентыбыз республиканың сәяси-икътисади тормышында зур вакыйга булган Дәүләт Советына Юлламасында кереш сүзен туган телебез белән башлап җибәрде. 2023 ел республикабызда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан ителде. Бу – телебезгә җаваплы булып, нәтиҗәлерәк эшләү өчен тагын бер зур сәбәп бар дигән сүз.

Марат Әхмәтов Сарманның Әлмәт авылындагы Морад Рәмзи исемендәге урта мәктәптә дини-әхлакый тәрбия белән милли белем бергәлегенең үзара матур нәтиҗәгә ирешү тәҗрибәсен башкаларга үрнәк итеп куйды:

– Күпчелек авыл мәктәпләрендә бала саны киму һәм якын шәһәрләргә, район үзәкләренә йөреп укыту тенденциясе күзәтелгән чорда Әлмәт мәктәбе үзенә ныклы һәм ышанычлы юл тапкан. Инде бетүгә бара торган, 26 балага калган ябылырга тиешле мәктәптә бүген 105 бала укый. Быел беренче сыйныфка 6 бала кергән, ә киләсе елда 20 бала килүе көтелә. Авыл мәктәбендә укырга теләүчеләр күп, хәтта чират торалар. Чаллыдан, башка районнардан күчеп кайтучы гаиләләр бар. Димәк, милләттәшләребез арасында үз балаларын туган телдә тәрбия һәм белем бирүгә битараф булмаган әти-әниләр бар. Киләчәктә дә эшегезне шулай уңышлы дәвам иттерсәгез иде.

Дин – туган телне, ә туган тел динне саклый. Комиссия җитәкчесе фикеренчә, милләтне тәрбияләүдә динне никадәр ныграк файдалана алабыз, шуның кадәр телебез язмышы өметлерәк булачак.

– Дин әһелләребез, мәчет, мәдрәсәләр белән һәр районда хакимият тыгыз элемтәдә булырга тиеш. Милләтебезнең киләчәк язмышы өчен башка кыйблабыз юк. Һәр районда 30–40ар мәчет бар. Бу – бик тә әһәмиятле тәрбия урыннары. Имам – авылның иң абруйлы кешесе. Аның сүзе үтемле була, – диде ул.

Ярты ел эчендә татар телендәге элмә такталарда хаталарны табу буенча халык контроле системасына 7 меңнән артык гариза килгән. Марат Әхмәтов район башлыкларыннан бу эшне шәхси контрольгә алуларын сорады.

– Кайбер районнарда бер генә мөрәҗәгать тә игътибарга алынмаган. Бу районда милләт язмышы белән кызыксынучылар аз булу, туган телгә мөнәсәбәт турында сөйли. Әгәр дә район җитәкчелеге милли җанлы булып, бу мәсьәләгә җитди караса, аны кыска срокта һәм идеаль рәвештә хәл итеп була, – диде ул.

Комиссия җитәкчесе милли мәгариф мәсьәләләренә дә тукталды.

– Телебез язмышы милли мәгарифкә бәйле. Милли мәгариф үзе милли мохиткә, тәрбиягә, мәдәниятка, дин һәм әхлакка, гаиләдәге телгә мөнәсәбәткә бәйле. Милләттәшләребезнең күңелендә булган рухи бушлыкны тутыру максаты белән бик күп чаралар уздырабыз. Районнардагы милли мохит, беренче чиратта, хакимият органнарының бу мәсьәләдәге шәхси үрнәгеннән тора. Милли җанлы, халык белән аңлашып эшли, аны инандыра ала торган җитәкчеләр була икән, телебезнең, традицияләребезнең киләчәге бар, – диде Дәүләт Советы Рәисе урынбасары.

Марат Әхмәтов белем бирү учреждениеләре өчен милли кадрлар әзерләү мәсьәләсенә дә аерым игътибар юнәлтергә чакырды.

– Милли мәгарифнең киләчәге турында сөйләшәбез икән, аны милли кадрларсыз күз алдына китерү мөмкин түгел. Бүген укытучы булырга теләүчеләр дә аздыр, бәлки, әмма алар өчен бөтен кызыксындыру чаралары да тудырылган. 45әр, 50 шәр мең халык яши торган районда милли кадрлар әзерләү мәсьәләсе проблема булырга тиеш түгел, – диде ул.

Азнакай районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Дамир Гыйләҗев телне өйрәтүдә өндәү һәм чакырулар белән уңай нәтиҗәләргә ирешеп булмый дигән фикерен әйтте.

– Мәҗбүри яраттырып булмый. Тел мәсьәләсендә дә мәҗбүрилек булырга тиеш түгел. Туган телгә мәхәббәт тәрбияләү гаиләдән башлана. Телгә карата уңай караш, кызыксыну уяту эше балалар бакчаларында, мәктәпләрдә дәвам итә, – диде Дамир Гыйләҗев. – Чәчәкнең сабагы, тамыры була. Иң матур өлеше – таҗлары. Соңгы вакытларда без күбрәк әнә шул өлешенә генә карап яши башладык. Бүген әти-әниләр балаларын татар сыйныфларына бирергә атлыгып тормыйлар. Балалар бер-берсе белән рус телендә аралаша. Әти-әниләр дә балалары белән рус телендә сөйләшә башлады. Хәтта саф татар авылларында да балаларның татарча сөйләшүе сирәгәеп бара. Бу – зур проблема. Яшен тизлегендә барган чорда туган телне саклау, мәдәни һәм рухи мирасыбызны киләчәк буынга түкми-чәчми җиткерү татар җанлы һәр кешене борчый торган мөһим мәсьәлә булырга тиеш.

Ләйсән САФИНА

Безнекеләр

СӨЙЛӘШЕП УТЫРАСЫ ИДЕ БЕР...

Сүз хезмәттәшебез Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ турында бара. Күп кенә укучыларыбызның теләге бу. Аңлашыла инде. Нигездә Россия, дөнья вакыйгаларына анализ ясап, нинди генә темалар күтәрми бит ул. Дөресен генә әйткәндә, үзебез дә шундый теләктә без. Әмма бер коллективта эшләсәк тә, сирәк күрешәбез. Рәшит Арча районындагы туган авылы Ташкичүне ташлап китмәде. Шунда торып кына эшли. Әңгәмә корырга җай чыкты үзе. 31 октябрь көнне 60 яшь тула аңа. Шул уңайдан хезмәттәшебез белән рәхәтләнеп фәлсәфә кордык.



:: Укытучы һөнәре алган, укытучы булып эшләгән кеше кинәт кенә әйдәп баручы журналистка әйләнде. Бәлки, бу кинәт кенә булмагандыр?

– Кинәт кенә булмады, әлбәттә. Балачактан ук яза идем. Башта район газетасында шигырьләр бастырылды, байтак шигырь 15–17 яшьлек чакларда язылган. Сиксәненче елларда бер хикәя дә язып карадым. Аны танылган хикәяче, бик үзенчәлекле стиль иясе булган язучы Радик Фәизовка күрсәттем. «Рәшит, бүтән хикәя язма яме, шигырьләр генә яз, шигырьләрең бик яхшы синең», – дигән җавап алдым. Педагогика институтына укырга кергәч (филолог булам дип, укытучы булам дигән фикер бик юк әле ул вакытта), мин иҗат серләре белән кызыксына башладым. Болгар академигы Михаил Арнаудовның «Психология литературного творчества» дигән ике кирпеч калынлыгындагы китабын укыдым. Кулга бирмиләр иде ул китапны, китапханәдә укырга туры килде. Беренче курска укырга кергәнче үк, татар әдәби тәнкыйтен су кебек эчә идем. Әмма институтта укыганда берни дә язмадым диярлек. Ничәнчедер курста белем алып йөргәндә, факультет деканы булып эшләүче Фоат Галимуллин үзенә чакырып алды да, бер йомыш кушып, «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясенә җибәрде. «Сиңа редакцияләрнең ишеген ачарга вакыт инде», – диде. Фоат Галимуллович мине ул чакта ук булачак редакция хезмәткәре итеп күргән, димәк. Газета редакциясенең җиденче каттагы коридорында беренче тапкыр атлап йөргәндә, кайчан булса да шуның «Җиденче каттан караш» дигән рубрикасына язмалар әзерләрмен дигән уй башка да килмәде. 1990 нчы елларда «Идел», «Казан утлары» журналларында шигырьләр, хикәяләр, әдәби тәнкыйть мәкаләләре бастыра идем. Күңелне борчыган мәсьәләләр турында публицистик язмалар бирергә теләк зур иде, тик ни сәбәпледер 2000 елга кадәр ул юнәлештә берни дә эшләнмәде. Яңа меңьеллыкка аяк баскач, «Татарстан яшьләре», «Мәгърифәт» газеталарында (бар иде шундый бик яхшы газета) күп язмалар бастыра башладым. Ул елларда мин мәктәптән тыш Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында өлкән фәнни хезмәткәр булып та эшли идем. Мәгариф министрлыгында «Мәктәп китапханәсе» сериясенең редакция советында әгъза идем. Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Хисам Камалов, Хәсән Сәрьян кебек классикларның томнарын мәктәп китапханәсе өчен кереш сүз язып, төзеп бирдем. Бик күп кенә исән шагыйрьләр, язучыларның китапларына кереш сүз яздым. Фирая ханым Зыятдинова, китабына кереш сүз язып бастырганнан соң: «Ниһаять, минем иҗатымны бәяләүче пәйда булды», – дигән иде. 2004 ел башында дип хәтерлим, Миңназыйм Сәфәров «Ватаным Татарстан»га редактор булгач ук, газетага эшкә чакырды. Җиде елдан соң гына мин, ниһаять, мәктәптән хезмәт кенәгәмне алып, редакциягә китереп бирдем. Бу вакытта инде чәчләрем яртылаш агарган, иллегә якынлашып килә идем. Шулай булгач, кинәттән түгел, бераз соңрак булмадымы икән газетага килү. 2008 елда Язучылар берлегеннән, китап итеп бастырырга тәкъдим итәргә дип, Татарстан китап нәшриятына кулъязма алып килүне сорадылар. Язылганнарның бер өлешен туплап, биш йөз битлек кулъязманы күтәреп киттем. Нәшриятның күченеп йөргән чагы иде, кулъязма редакторга тапшырылды, редактор кинәт кенә үлеп китте, мин китап чыгару артыннан йөрмәдем, шулай итеп ул чыкмый калды. Иҗат серләре турында «Кальбеңдә ни сер бар, каләм?» дигән китабым бар минем. Тәкъдир шулай язылган, шул юл буйлап атлаганмын инде. Акрынлап, әзерләнеп килдем язу дигән эшкә. Ә теге әйдәп баручы дигән сүзләрне төшереп калдырыйк, әйдә.

> Журналистикадагы урыным турында мин бөтенләй уйламыйм, алай югары бәяләп тә мәшәкатьләнмим үземне. Бу мине бөтенләй кызыксындырмый.

:: Авылда яшәгәч, мәктәп тормышын, укучыларны бүген дә яхшы беләсеңдер, мөгаен?

– Мәктәпкә аяк басмаганыма ун ел булып килә. Редакциягә күчкәч, бер-ике ел ярты ставкага укытып йөрдем әле. Журналистка редакциядән тыш тагын кайда булса да ярты ставкага эшләргә кирәктер дип саныйм. Бер тармакны булса да эченнән яхшы белергә булыша. Мәктәптә эшләгән елларда мәгариф темасына күп яздым, чөнки проблемаларын яхшы белә идем. Үземнең улым белән кызым БДИ биргәндә, мин шул теманы еш күтәрдем, алар вузга кабул ителгәндә, шул процессны киң яктырттым. Хәзер, игътибар белән карасагыз, ул темаларны байтактан күтәргәнем юк. Яхшы итеп белмәгән нәрсә турында янып-көеп, укучыны да уйландыра торган итеп язып булмый чөнки. Укучы балалар белән урамда сөйләшеп йөргәлим, мәктәп турында да сорашам. Укытучылардан да сорашам кайвакыт. Тик сорашып кына эшнең асылын төшенеп җитеп булмый барыбер. Мәктәптә мотивация дигән нәрсә җитмәде беркайчан да. Югыйсә әллә ниләр эшләнер иде. Укырга теләмәгән укучыны укытудан да мәгънәсезрәк эш юк. Мәгариф өлкәсендә үзгәрешләрне менә шул мотивация булдырудан башларга кирәктер. Ә болай хәзерге мәктәпнең матди-техник тәэмин ителеше начар түгелдер дип беләм. Тик белемгә сусаган укучы булмаса, мәгълүмати технологияләр белән дә, башка техник чаралар белән дә бик әллә ни кылана алмыйсың.

:: Татар теленең киләчәге турында уйланасыңдыр?

– Мәккә шәһәренең уртасында саф татар телендә сөйләшүче кеше белән очраштым мин бервакыт. Ул үзен әфганлы үзбәк дип таныштырды, Мәккәдә төпләнеп яши, шунда бизнесы бар, Татарстанны да, Россияне дә күргәне юк, ләкин татарча, рус алынмалары кулланмыйча, бик чиста сөйләшә иде. Соңыннан ул үзе дә: «Безнең бабайлар татар булган», – диде. Татар теленең киләчәге дигәндә, менә шулар турында уйлыйм. Җир шарында татарча сөйләшә торган күпме кеше барлыгын да белмибез. Татарча гына белеп, Мәккәдә адашмыйсың. Бангладешта сөйләшә-аңлаша аласың. Төркиядә дә ач калмыйсың. Сүриядә төркиләр күп дип беләм. Урта Азия республикалары турында әйтеп тормыйм. Кытайда уйгурлар эзәрлекләнмәсә, туган телебез белән анда да югалмас идек. Социаль челтәрләрдә казахлар, үзбәкләр белән бик җиңел аңлашам. Якын киләчәктә татар теленә күтәрелү өчен, дөньякүләм мәйданга чыгу өчен, юллар ачылу ихтималы зур дип уйлыйм. Бик тиз үзгәрә торган дөньяда яшибез. Туган тел турында язмалар да бастыргаладым. Әмма ул юнәлештә даими эшләмәдем. Бар нәрсәгә дә өлгереп булмый. Авылда яшәү дә бераз комачаулады инде. Гел аралашып, көчләрне бер йодрыкка туплауны сорый андый киң проблемалар.

:: Авылдан шәһәргә күчену теләге булмадымы?

– Вуз тәмамлаганда, диплом яклап коридорга аяк атлагач, имтихан комиссиясенең рәисе, Казан дәүләт университеты профессоры Вахит ага Хаков артымнан ук чыгып, миңа үзләренә аспирантурага килергә тәкъдим ясады. Шәһәрдә калырга шанс бирә иде бу миңа, әмма баш тарттым, авылга кайтам, дидем. Мәктәптә ике ел эшләгәннән соң, пединститутның кафедра мөдире Фәрит Хатыйпов, телеграмма сугып, Казанга чакырды, кафедрада эш тәкъдим итте. Тәкъдимнең анысыннан да баш тартырга туры килде, ул вакытта инде Аллаһ үзенең тәкъдире белән мине авылга нык итеп беркетеп куйган иде, теләсәм дә, китә алмаячак идем. Мин шул язылган тәкъдирдән бик риза булып яшим. Артка борылып карыйм да аңлыйм: минем өчен иң яхшы юл шул булган. Шәһәрдә калсам, бик тиз тормыш төбенә төшкән, югалган булыр идем. Хәзерге авыл туксанынчы еллардагы авылдан нык аерыла. Авыр кул хезмәте юк диярлек, комфорт, кыскасы. Шуңа күрә авылдан шәһәргә күчү теләге юк.

:: Нилар белән шөгыльләнәсең, ничек тормыш алып барасың?

– «Бриллиантовая рука» дигән фильмда бугай, җинаятьче төшендә үзен хезмәт хакына яшәргә хөкем иткәннәрен күреп, тиргә батып уяна.

> Хезмәт хакым белән, эшләгәнем белән яшәдем. Һәрвакыт диярлек ике сыер асрадым. Зур табыш бирмәсә дә, ит, сөт, майны чикләп кулланмыйсың. Аннан соң терлек тоту физик эш белән шөгыльләнергә мәҗбүр итә. Минем сәламәтлегем өчен бу кирәк.

:: Язмаларыңны даими укучылар беләдер, синдә фаразлау бик көчле. Шулай булачак дигәнең иртәме-соңмы чынга аша. Бу тәҗрибәдән киләме, әллә инде...

– Күп вакыт арифметика дигән бик гади фән булыша. 2021 елның декабрендә быелга фаразлар язганда: «...2022 елда, мөгаен, төп халыкара вакыйгалар Көнбатыш – Россия, Көнбатыш – Кытай яссылыгында барыр... Учак безнең көнбатыш чикләрдә ягылса, бер дә яхшыга түгел», – дигән сүзләр әйткән идем. Боларны фаразлауның бер дә кыенлыгы юк иде, чөнки вакыйгалар өлгереп-пешеп җиткән иде. Төп эш коралым – телефоным. Җир шарының төрле почмакларыннан тәүлек эчендә йөзләгән хәбәр алам. Төнлә дә тынмый телефон. Тыныч йоклыйсы килсә, интернетны өзеп ятам. Шулай да төнгә берничә тапкыр уянып, хәбәрләрне күзәтеп чыгам. Шулай эшләгәндә, тарих сабакларын да белсәң, вакыйгаларның кай тарафка үсәсен чамалау кыен түгел. Ә болай үзем белән иртәгә ни буласын да белмим мин. Адәм баласына киләчәкне белү сәләте бирелмәгән.

:: Анкеталардан күренгәнчә, укучылар язмаларыңны ятарып укый. Югыйсә сәясәткә бар кешенең дә теше үтмәскә дә мөмкин бит. Көче нәрсәдә дип уйлыйсың?

– Язганда, ихлас булырга кирәк. Син ялгышырга мөмкин, бу кичерелә. Укучы фальшьне кичерми бер дә, ул аны тиз тоя.

:: Укучыларның шәхсән үзеңә шалтыратып фикер алышканнары бармы?

– Газета укучылар шалтырата, теләктәшлек белдерүләре сөендерә. Уртак танышлар аша: «Сөйләшеп утырасы иде бер», – дип эндәшүчеләр дә булгалый. Контактка кергән газета укучыларга рәхмәтлемен.

:: Авылда яшәп иҗат иткәч, аралашу мөмкинлеге чикләрәк. Бәлки, синең үзең эшләгән «Ватаным Татарстан» редакциясе коллективына да әйтәсе сүзләрең, җиткерәсе киңәшләрең бардыр?

– Мин хәзер шундый яшьтә: коллективта шаулап, аралашып яшәү еллары узган. Хезмәт коллективы – үзгәреп, алышынып тора торган нәрсә бит ул. Өлкәннәр китә, яшьләр килә. Яшьләр безгә өстәнрәк тә карарга мөмкиннәр, уртак тел табылмаса да гаҗәп түгел. Туган авыл мәктәбенә кайтып эшли башлаганда, яше пенсиягә якынлашып килүче Равил абый Габраупов директор иде. Коллективның яртысы ир-атлардан тора. Дәресләрдән соң җыелышып, сөйләшеп утырабыз. Равил абый, өлкән кеше буларак, безгә киңәшләр бирә. «Егетләр, – ди, – мөмкинлек чыкса, яхшылык эшләгез, җае чыкса, эшләми калмагыз». Яшьләргә шул сүзләрне хәтерләренә салырга киңәш итәр идем. Танылган мөселман галименең кыйммәтле бер фикере бар тагын: «Җимеш агачы кебек булыгыз, – ди ул. – Сиңа таш аталар, син җимеш ыргытып җавап бирәсең». Моңа ирешү кыен. Нәфесне бик нык өйрәтергә, чыныктырырга кирәк. Сирәкләр генә ирешә торган бәхет бу.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

БУЫННАРНЫ УТЫРТУЧЫ РАДИК СОЛТАНОВ:

«ДӘВАЛАП БЕТЕРГӘЧ, КУЛ ЯБЫШМЫЙ БАШЛЫЙ»

Бөкрене турайта, тайпылган буыннар, чыккан сөякләрне урынына утырта... Арча районының Гөберчәк авылында яшәүче Радик Солтанов меңнән артык кешене сәламәтлеккә кинәндергән. Юк, ул табиб түгел, гади тракторчы. Шуңа да карамастан, аның басудан эштән кайтуын көтеп торучылар аз түгел. Авыруларны кире бормый, тик кояш баегач, килмәскә куша.

Радик Солтановка дәвалау сәләте әнисе Минсәгыйрәдән күчкән. Аның әбисе дә чыккан сөякләрне утырта торган булган. Радик кечкенә чагыннан ук әнисенең ничек дәвалавын күреп үскән. Теге яки бу сөякне ничек утыртасы дип сораулар да биргәләгән. Әнисенең кул көче җитми башлагач, аңа булышырга туры килә. Күрәзәче дә, өшкерүче дә түгел, ниндидер шифалы мазьлар да ясап сатмый.

– Барысы да шул әнигә булышудан башланды. Тартып утыртырга көч кирәк бит. Элек Әлмәт якларына шабашкага йөргәндә дә, ярдәм сорап еш киләләр иде. Бу эш белән утыз елга якын шөгыльләнәм. Туктап та торган идем, тик әни ташламаска кушты, – ди 58 яшьлек дәвачы Радик Солтанов.

Радик Солтанов эштән арып кайтса да, бусагасын атлап керүчеләрне кире бормый. Дөрес, хәзер аңа күпләр алдан язылып килә икән. Ни өчен дигәндә, эштә булуы бар. Өйгә кайткач, мал-туарын карарга кирәк. Без килгәндә, хатыны Гөлинә белән абзарда кайнашкан чагы иде. Безнең кебек эшеннән бүлүчеләр җитәрлек, димәк. Дәвачы анысына сүз әйтми. Тик күп сораулар биреп аптыратканны яратмый. Элек бигрәк тә аз сүзле булган, кешеләр белән аралашып, үзе дә ачылып киткән.

– Синең табиб дипломың бармы? Кайда укыдың? Барысын да кайдан беләсең? Болар – минем яратмаган сораулар. Мин аңлатырга тиешмени, нәрсәгә? Игъланнар биргәнем дә, берәүне дә махсус чакырганым да юк. Гадәттә таныш-белешләре аша сорашып киләләр, – ди Радик әфәнде.

Аның тагын бер еш ишетә торган соравы бар әле: «Кешене дәвалаганда, син нишләп читкә карыйсың?»

– Күз белән карау мөһим түгел. Мин кулларым белән дәвалыйм. Сынган, тайган җирне шундук тоям. Әйтик, умыртка баганасын утырта башлыйм икән, кул үзеннән-үзе шунда ябыша. Утырып беткәч кенә ябышудан туктый. Бик кызык бит. Моны кешегә әйтеп аңлатып булмый, – ди әңгәмәдәшем.

Кайбер дәвачылар: «Кешеләрне кабул итми торсам, бармак башлары чиләнә башлый», – ди. Радик әфәнде андый нәрсәдән интекми. Тик кешенең чирен үзенә алып, кәефсезләнгән чаклары аз түгел. Монысы инде баш авыртуын дәвалаган очракларга кагыла. «Кешегә ярдәм итү – сөенеч, күңелгә рәхәт булып китә. Тик үземнең дә сәламәтлек бетеп килә шул инде. Элек энергиям күбрәк иде. Эчкән кешене айнытканда, кулларымнан җылы бәрелеп тора иде», – ди ул.

Кайберәүләр аңа гомер буе рәхмәтле. Бер хатынга табиблар бот сөягенә операция ясарга тәкъдим иткән булган. Бәясе дә кесәгә сугарлык – 140 мең сум. Пычак астына кереп ятарга курыккан ул. Радик Солтанов аны өч сеанстан соң ук аякка бастырган. Менә шундый могҗиза! Хәзер теге ханым чатыр чабып йөри, ди. Юл фаҗигасеннән соң бөкре калган иргә дә кулларының шифасы тигән. Аңа да сәламәт, бәхетле тормышына кайту өчен өч көн җиткән. Акчаны да кул әҗере өчен генә ала. Файдасы тисә, калдырыгыз, ди. Биргәннәр һәм бирмәгәннәр бар.

Күп кешенең хәзер – умырткасында бүсер. Дару гына булышмый. Радик Солтанов әнә шулай ди. Бүсер электән булса, аңа тими. Файда китерәм дип, кешегә зыян эшлисе килми аның. Бүсере бетсә дә, шул урын сызлый торган булып калырга мөмкин. Шуңа күрә яңа чыккан бүсерләрне генә дәвалый. Ярдәм сорап килүчеләр арасында табиблар да бар. Аңа күбрәк Биектау, Балтач, Әтнә якларыннан киләләр. Кайберәүләр иртәнге сәгать дүрттә үк ишеген шакый.

– Бу чирләрне экологиядән, хәрәкәт җитмәүдән, тукланудан күрәм. 1985 елга кадәр бәрәңге корты булмады. Хәзер өчәр тапкыр агуларга туры килә. Ашаудан да күп нәрсә тора. Оннының да сыйфаты югалды. Элек симез кешеләр юк иде, хәзер күп. Барыбыз да тәмлене ярата, әмма хәрәкәт юк. Без чишмәдән су китереп үстек. Кер юганда өчәр сәгать чират көтә идек. Салкын су белән кер югач, кул сызлый. Шуңа күрә кулларны сакларга кирәк. Тәм-томга кызыкмагыз, ешрак җәяү йөрергә тырышыгыз. Хәрәкәтле тормыш бәрәкәтле дә булачак, – ди халык табибы.

Сәрия МИФТАХОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗӘК САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ КАРАР

25 октябрь, 2022 ел | Казан ш. | № 2/10

2022 елның сентябрендә төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен раслау турында

Тиешле мәгълүматны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга бер календарь ае эчендә тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен билгеләү буенча Эш төркеменең «2022 елның сентябрендә төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләре турында» 6 октябрь, 2022 ел, № 105 карарын тикшергәннән соң, «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалы тарафыннан яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 11 ноябрь, 2010 ел, № 35/392 карары белән расланган Төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы һәр сәяси партия эшчәнлеген бер календарь ае эчендә яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү тәртибенең VI бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе **карар бирә**:

1. 2022 елның сентябрендә төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы һәр сәяси партия эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен (Эш төркеменең 6 октябрь, 2022 ел, № 105 карарында урын алган) расларга.
2. «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖ тарафыннан гамәлгә куелган һәм эшләтелә торган «Татарстан – Яңа Гасыр» телевидениесе» төбәк телеканалының һәм «Татарстан – Яңа Гасыр» радиосы» – «Болгар» радиосы» радиопрограммасы» төбәк радиоканалының 2022 елның сентябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген бер календарь ае эчендә тигез күләмдә яктырту турында «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалында яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәве турында бәяләмә чыгарырга.
3. Бу карарны «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖгә, «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстандагы төбәк бүлегенә, «Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе» сәяси партиясенең Татарстандагы төбәк бүлегенә җибәрергә.
4. Бу карарны бастырып чыгару өчен «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарына җибәрергә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.
5. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рәисе урынбасары А.А. Нефедовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе — А.С. Кондратьев

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе
Секретаре вазыйфаларын башкаручы — Р.Р. Вәлиуллова

АШЫГЫЧ ОПЕРАЦИЯГӘ МОХТАҖ ҖЫРЧЫ ДӘНИФ ШӘРӘФЕТДИНОВ:

«Минем бердәнбер таянычым – ышаныч»

Дәниф Шәрәфетдинов Казанда концертта катнашачак икән! Шушы хәбәрне ишеткәч, гадәттәгечә, җырчының хәл-әхвәлен белешергә булдык. Юк икән шул, килми дә, катнашмый да икән... «Хәлем – хәл бит әле», – диде ул, авыр сулап. Баксаң, икенче күзе дә сукырайган икән. Бу хәбәр өнсез калдырды. Ничек тә ярдәм итәсе килде. Дәниф исә: «Бу хәбәрне дөньяга чыгармый торыгыз әле, сезне бит әни дә укый, аны хәсрәткә саласым килми», – диде.

Гомер буе якыннарын кайгырткан кеше, соңгы чиккә җиткәндә дә, шушы гадәтенә тугры кала икән. Хәле көннән-көн авырайса да, квота булыр, бушлай операция ясата алырмын, дип юаткан ул үзен. Квота дигәне генә офыкта күренми.

– Күрүем җәй көне үк коточкыч начарайды. Бу инде – Бехтеров чиренең бер мәкерле һөҗүме. Мәскәү профессоры, офтальмолог Михаил Коновалов исә, дәвалау дөрес юнәлештә булмаган, дип тә әйтте. Мин аңа бөтен анализларымны юллап, консультация алган идем. Билгеле, күзгә операцияне Мәскәүдә ясатсаң яхшы булыр иде, ләкин аңа кадәр умыртка сөягендәге ялкынсынуны дәваларга кирәк. Чыннан да, без күзне дәваларга омтылдык, баксаң, башта шушы ялкынсынуга алынырга кирәк булган икән. Инде хәзер, ахыры хәерле булсын, дип теләргә кала. Минем көн туса да, кич җитсә дә, бөтен таянычым – ышаныч. Ансыз булмый. Бөтен уйлаганым – балаларым. Алар сәламәт булсын, сәламәт булсалар, бәхетле дә булырлар. Әлегәчә кулдан килгәнчә ярдәм итеп тора идем дә бит... Алар хәлне аңлыйлар, әти, дип өзгәләнеп торалар.

Икеләнгән чакларда хәлеңне аңлап, уйларыңны дөрес юлга юнәлтүче дустың булсын, дип, тикмәгә генә әйтмиләр. Бәхеткә, Дәниф Шәрәфетдиновның андый дусты бар. Җырчы Ринас Әхмәтов булмаса, аның хәлен белгән кеше дә булмас иде. Үзе бу хакта менә нәрсәләр сөйли:

– Без Дәниф абый белән шактый еллар таныш, инде хәзер гаилә дусларына әйләнеп беттек. Ул – көчле рухлы, эчендәгесен бик сирәкләргә генә ача торган горур кеше. Мин аның ничек яшәгәнен, бөтенләй үк булмаса да, ниләр уйлаганын беләмдер, мөгаен. Ярдәм кирәк вакытта, каядыр алып барып кайтырга булса, беркайчан кире какканым юк. Беркөн шулай чишмә суы алып кайттык. Гадәттә ишек янында Дәниф абый каршы ала иде. Бу юлы куллары белән стеналарны капшап чыгып барганын күргәч, ир кеше булсам да әйтим, елап җибәрдем. Хөрмәт иткән абзый бит ул минем. Аны шушы хәлдә күрү бик авыр булды. Элегрәк, бердәнбер күзенең томалана башлавын белгәч тә, әйдә, халыкка мөрәҗәгать итик әле, дидем. Ул баш тартты. Дәниф абый кире кага икән, бернәрсә эшләп булмый. Бу юлы авырлык белән ризалашты. Сөйләшә торгач: «Ринас, әле бит шул бер исән күзем белән аранжировкалар ясап, хөкүмәт биргән 8 мең сум пенсиямә өстәп, гаиләмне ашата, улым белән кызыма да булышкалый идем. Ә хәзер оныкларымны да күрә алмам микәнни инде?» – дип, ул да елап җибәрде. Тәвәккәлләп, социаль челтәрләргә, Дәниф Шәрәфетдиновның күзенә операция ясау өчен зур суммада акча кирәклеге турында яздым. Дөрес, бик авыр заманда яшибез. Әмма бу хәбәрне, әйтик, тәмәке тартучы да укый торгандыр. Тәмәкенең бәясе – 200 сум. Бер кап тәмәке алмыйча торып, акчасын шушы ярдәмгә салса, нинди зур игелек булыр иде. Миллион сумнан артык сумма икәнлеген аңлыйбыз инде... Шулай да акрынлап тамчыдан күл җыелыр иде.

Ринас Әхмәтов, хәбәр чыгу белән, ярдәм итүчеләр барлыкка сөенә. Аның ышанычы зурдан. Без дә яхшыга өметләнәбез. Ярдәм итәргә теләк белдерүчеләр өчен исәп-хисап счетын да тәкъдим итәбез.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

Дәниф Шәрәфетдиновка тиз арада кыйммәтле операция кирәк (СКВОЗНАЯ ПЕРЕСАДКА РОГОВИЦЫ)
Получатель: ШАРАФЕТДИНОВ ДАНИФ ДАНИЛОВИЧ
Номер счёта: 40817810662031714365
Банк получателя: ОТДЕЛЕНИЕ «БАНК ТАТАРСТАН» N 8610 ПАО СБЕРБАНК
БИК: 049205603
Корр. счёт: 30101810600000000603
ИНН: 7707083893
КПП: 16550200
Номер карты Сбер: 2202200600704942
Телефон: 89370423783.

ЙӨРӘК ЭШЕ

«ТАТНЕФТЬ» КОМПАНИЯСЕ ЯРДӘМЕ БЕЛӘН ДОНОРНЫҢ БЕР КӨНЕ БӘЙРӘМГӘ ӘВЕРЕЛДЕ

Алар игелекле гамәл башкаруы турында кычкырып йөрми. Моның өчен акча да, дәрәҗә дә сорамый. Күңел салган эшен йөрәк кушуы буенча намус белән башкара бирә. Сүзем – кеше гомерен саклап калуга зур өлеш керткән донорлар турында. Бу атнада Республика кан үзәгендә донорның бер көне зур бәйрәмгә әверелде. Биредә «Милли музыка көне» дип исемләнгән көзге донорлык акциясе үтте. «Татнефть» компаниясе ярдәме белән оештырылган чарада «ВТ» хәбәрчесе дә булып кайтты.

Иртәнге сигездә башкаланың Кан үзәгендә алма төшәрлек тә урын юк иде. Теркәү өстәле янында су буе чират җыелган. Олысы-кечесе көнен әнә шундый изге гамәлдән башларга ашыга. Һәркем сабыр гына үз чиратын көтә. Гадәттә андый чакта күзәтелә торган этеш-төртеш, тавышлануның эзе дә юк биредә. Ни гаҗәп, чиратта басып торучыларның яртысын диярлек студентлар тәшкил итә.

Россия дәүләт хокук институтының Казандагы бүлегендә укучы 21 яшьлек студент Алинә сигезенче тапкыр кан тапшыра икән. «Пандемия вакытында кан аеруча кирәк булган чорда беренче тапкыр тапшырдым. Телевизордан игълан күргәч, икенче көнне үк бирегә килдем. Хәзер өч айга бер тапкыр кан тапшырып торам. Кешеләргә шул рәвешле файда китерә алуыма шатмын», – ди ул. Чая кыз эшне тиз тотты. Рәсми кәгазьләрне тутырып, кан тапшыргач, укырга йөгерде ул.

Анна Арахамия

Казанда яшәүче «Мактаулы донор» – 34 яшьлек Екатерина Фролова да беренче тапкыр студент чакта кан тапшырган икән. Биредә ул – күптән үз кеше. «Кан тапшырырга бәйрәмгә килгәндәй барам», – дип елмая ул үзе.

Екатерина 2007 елдан бирле донор исемен йөртә. Шул вакыт эчендә ул 100 тапкырдан артык кан тапшырган. 1990 елларда әтисе дә донор булган.

– Беренче тапкыр кан биргәндә миңа 19 яшь иде. Казан авиация институтында укып йөргән чак. Кан бирдем дә шул ук көнне зачет тапшырырга киттем. Зачетны бирә алмадым, аның каравы донор булдым. Киләчәктә дә көчемнән килгәнчә кешеләргә ярдәм итәсем килә, – ди Екатерина.

Донорлар белән сөйләшеп торган арада, фойеда үзебезнең татар халык җыры ишетелде. Баксаң, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге Татар дәүләт фольклор ансамбле донорларга концерт программасы да әзерләгән икән. Уен коралларында яңгыраган милли көйләребезне, җыр-биюне тамаша кылган күпләр чиратта торганлыгын да онытты. Хәтта кан тапшыру бүлмәсендә дә моңлы курай тавышы яңгырады.

«Гадәттәгечә кан тапшырырга килгән җирдән шундый матур бәйрәмгә эләктем. Хәзер ничек эшкә барасы инде дип аптырап торам», – ди янымда басып торган Эльмира Садыйкова. 9 нчы номерлы шәһәр балалар хастаханәсендә эшләүче белгеч өченче ел рәттән кан тапшыра икән.

– Бу эшкә күңел кушканга алындым. Коронавирус белән авырган, вакцина ясаткан чорда гына кан тапшырмыйча тордым. Хәзер шундый чор – кан һичшиксез кирәк булырга мөмкин. Хәзерге вакытта Тайландта стажировка узучы кызым да даими рәвештә кан тапшыра. Бер үк вакытта ул сөяк җелеге доноры да булып тора, – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

Бу көнне донорлар күңелләренә рухи азык кына алып калмыйча, истәлекле бүләкләргә дә ия булды. Кан тапшырып чыгучыларны татлы чәкчәк белән дә сыйладылар.

– Форсаттан файдаланып, шушы зур чараны оештырырга ярдәм иткән «Татнефть» компаниясенә зур рәхмәтебезне белдерәсебез килә. Без әлеге фонд тарафыннан оештырылган бәйгедә грант оттык. Әлеге грант акчасына менә шундый игелекле акцияләр уздырабыз, – диде чараны оештыручыларның берсе – DonorSearch.org кан донорлары берләшмәсе җитәкчесе Юлия Исмәгыйлева. Ул үзе дә тәҗрибәле донор икән. Бу юлы Юлия унсигезенче тапкыр кан тапшырды.

Гомумән алганда, көн дәвамында 138 донор 62 литр кан тапшырды ул көнне. Республика кан үзәге баш табибы Рамил Тураев сүзләренә караганда, бүген Татарстанда 70 меңгә якын донор теркәлгән. Республикада 12 меңнән артык Россия һәм СССРның атказанган доноры исәпләнә. Ел буена Татарстанда уртача 55 тонна кан запасы әзерләнә. Бу барлык дәвалау оешмаларын кан белән тәэмин итәргә җитә. Запаска да кала. Дөнья хәлен белеп булмый бит.

– Донорлык – тәүлек, ел әйләнәсе кирәкле гамәл. Пандемия чорында донорлар бераз кимеп алды. Әмма аннары алар кабат кайтты. Бездә көненә уртача 120–130 кеше кан тапшыра. Бүген донорның гадәти бер көнен шундый зур бәйрәмгә әверелдерәсебез килде. Бирегә килеп, шушы изге эшкә үз өлешен керткән һәр донорга чиксез рәхмәт әйтәсем килә, – диде баш табиб.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

реклама 16+

ДОНОР БУЛУНЫҢ ӨСТЕНЛЕКЛӘРЕ

✓ Закон нигезендә, 18 яше тулган, үзен яхшы хис иткән, гәүдә авырлыгы 50 килограммнан да ким булмаган сау-сәламәт һәркем донор буларак кан тапшыра ала.
✓ Россия Хезмәт кодексы нигезендә, донор кан тапшырган көнне ял итәргә мөмкин. Аннан тыш тагын бер көн өстәмә түләүле ял бирелә. Аны бер ел эчендә кулланырга кирәк. Ялны еллык отпуск чорында ике көн рәттән алырга да мөмкин.
✓ Кан тапшырган кешегә туклану өчен 903 сум акча түләнә. Кан тапшыргач, белешмә язалар һәм шунда ук кассадан акча аласың. Кан бирәсеңме, плазмамы, башка компонентмы – бер үк сумма каралган.
✓ «Мактаулы донор» исә һәр елны үзенә уңайлы вакытта түләүле ял алырга хокуклы. Моннан тыш ул дәүләт һәм муниципаль сәламәтлек саклау оешмаларында чиратсыз дәвалана, шифаханәләрдә дәвалану өчен, эш-уку урыныннан бирелүче ташламалы юлламаны чиратсыз алырга хокуклы. «Мактаулы донор»ларга елга бер тапкыр акча да түләнә. Аның күләме ел саен индексацияләнә. Быел ул 15713 сум 84 тиен тәшкил итә. Моннан тыш «Мактаулы донор»лар җәмәгать транспортында ташламалы бәядән йөри ала.

КАНАТЛЫ ТАНЫШЛАР

Яшәеш

Урамга чыксам, таныш тавышлар ишетеп, каршы яктагы күршеләрнең миләшенә борылдым. Ялгышмаганмын. Агачлары тулы кош. Берсе килә, берсе китә: барысы да, мәш килеп, миләш ашый. Миләш чыпчыклары! Аларның тавышын башка кошларныкы белән бутап булмый. Өстәвенә барлы-юклы бер-ике генә тавыш түгел, көтүләре белән йөриләр, көтүләре белән – хор белән чыркылдашалар.

Елның шушы вакыты җитсә, кайбер елны кышкы яккарак калалар, бу танышлар күршеләрнең шау миләштән сыгылып утырган агачларын күз ачып йомганчы бөтен тәлгәшләрен – бөртеген дә калдырмый сыпырып китәләр. Быел да гадәтләренә тугры калдылар. Шул көнне кичкә агачлары яртылаш бушап калса, икенче көнгә инде сыңар миләш тә калмаган иде. Хәтта аскы ботакларга кадәр төшеп ашаганнар (миләш агачы юл буенда булганлыктан, тавыштан куркыпмы, башка сәбәп беләнме, кайбер елны аскы өлешләре кала иде).

Бу кошларны элек авылда күргән булмады дисәм дә, ялгыш булмас (ә хәзер күгәрченнәр бик сирәк күренә. Алар күбрәк ындыр табакларында. Кайчандыр һәр хуҗалыкта, лапаста тавыклар белән бергә ашап-яшәп диярлек көн күрсәләр, бөтен тәрәзә йөзлекләрен «бизәкләп» бетерсәләр, безнең авылда, мәсәлән, алар бөтенләй юк). Миләшләр кыш көне дә үзләре коелып беткәнче диярлек утыралар иде дип хәтерлим. Баштарак без миләш чыпчыкларын танымый да идек әле. Яз көне себер зелпесен (жимолостьны), күрми калсаң, сәгате-минуты белән юк итәләр, аннан беренче җиләкләр өлгерә башлауга, викториягә күчәләр. Аннан кызыл шомыртка, чиягә... «Нинди кошлар икән бу?» – дип аптырашкан истә. Чөнки тавышлары ишетелә, үзләре шулкадәр җитез, бик сак ашыйлар, якынлашканыңны сизүгә, инде очып та китәләр, күрми дә каласың. Соңгы елларда ешладылар, инде таныйбыз, дуслар килгән икән, диешәбез.

vk.com

Быел җәен себер зелпесенә дә, викториягә дә килүче булмады (бер елны түзә алмагач, видеокассеталар лентасын агачка, виктория түтәле өстенә сузып та караган идек). Тамаклары тук булганмы, башка урында сыйнигъмәт тапканнармы? Ә менә кызыл шомырт өлгергәч, канатлы танышлар табылды. Күзгә күренми генә, агачның иң өске ботакларында чыркылдаша-чыркылдаша сыйландылар. Аскы яктан мин җыям, өстә алар сыйлана. Кумадым. Ашасыннар, барыбер өске яклары кибеп бетә, мин әйтәм.

Кызыл шомырт – иң яраткан куагым, иң яраткан җимешем. Бик күңелле балачак хатирәләренә бәйле куак ул. Безнең бакчада әле ул моннан ун-унбиш еллап элек кенә үсә башлады. Бала чакта исә тирәбездә (авылда да иде бугай) ике бакчада гына үсә: күрше Гыйният бабайларныкы ишегалды бакчаларында, уртада. Аны үрелеп, качып-посып ашап булмый. Ә менә Йосып бабайларныкы су буена төшә торган тыкрык буенда. Киң булып, җәелеп үскән шушы куак ярты җәй буе безгә сыйланырга җитә иде. Су коенырга (кимендә 4–5 тапкыр), су буена табак-савыт, башка әйберләр юарга төшсәк-менсәк тә (боларының саны юк), шушы тәмле куак янына тукталмый китми идек. Койма эчендә булса да, төрле яклап ашыйбыз. Ничек орышмаганнар, кумаганнар, бер көтү бала-чага булсак та, бер сүз әйтмиләр иде! Үзләрендә дә дүрт малай үсә ләбаса!

Инде бу нигездә чит кешеләр яши. Әле Сәүбән абый (Йосып бабайның улы) исән чакта, бу куакларны әйләндереп алган коймалар тузып, алар иркендә калгач, сорап, бер туйрасын бакчабызга утырткан идем. Үсте, матурланды. Дөрес, яшь ботакларын киметеп торабыз, алардагы кебек җәелеп үсми. Әмма үзебезгә һәм миләш чыпчыкларына җитә. Кызыл шомырт өлгергән саен, минем дә хатирәләр яңара, кошлар да онытмый, эзләп табып, килеп җитәләр. Миләш чыпчыкларын күргәч, кызыл шомырт искә төште менә...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 6715 данә
Гомуми тираж – 15318 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 360

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).
16+